# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Лебяжье авыл җирлеге составына керүче Сакон авылы торак пунктында**

2020 елның 12 ноябре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Лебяжье авыл җирлеге составына керүче Сакон авылы торак пунктында гражданнар җыены нигезендә

## КАРАР ИТТЕ:

1. 2021 елда Лебяжье авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан, көндезге уку студентларыннан, Россия Армиясе сафларына ашыгыч хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, гражданнарның үзара салымын 500 сум күләмендә кертергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге максатларга җибәрергә:

- торак пунктта урамнарны яктырту;
- җәйге һәм кышкы чорда юлларны карап тоту (үләннәрне чаптыру, карны чистарту);
- Сакон торак пунктында юлларны төзекләндерү һәм төзү;
- территорияне төзекләндерү;
- Сакон авылында, Үзәк урамда балалар өчен уен мәйданчыгы сатып алу һәм урнаштыру;
- Бөек Ватан сугышында һәлак булган сугышчыларга обелиск сатып алу һәм урнаштыру.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Лебяжье авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Лебяжье авыл җирлеге, Лебяжье авылы, Үзәк ур., 27А йорт һәм Сакон ав., Үзәк ур., 39 йорт адреслары буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче,**
**Лебяжье авыл җирлеге башлыгы** **Д.Ә. Гыйләҗев**